**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күәм авыл җирлеге Җилгелде торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"20" ноябрь 2020 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Җилгелде торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Җилгелде авылы территориясендә 2021 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Җилгелде торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

а) Күмү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:

Җилгелде авылында зиратны койма белән әйләндереп алу өчен төзелеш материаллары алу.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Җилгелде авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Җилгелде авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Күәм авыл җирлеге башлыгы Гатауллин Р.Р.